КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 3 март г.Казань № 166

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарның үтәлүен дәүләт тикшерүендә тоту турында» 2008 ел, 15 июль, 509 нчы карары белән расланган Җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарның үтәлүен дәүләт тикшерүендә тоту тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарның үтәлүен дәүләт тикшерүендә тоту турында» 2008 ел, 15 июль, 509 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 27 ноябрь, 922 нче; 2018 ел, 9 август, 648 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарның үтәлүен дәүләт тикшерүендә тоту тәртибенә, 4 бүлекнең 4.8 нче пунктындагы икенче абзацына «нигезендә» сүзләреннән соң «, шулай ук ачыкланган бозуларны бетерү турында элегрәк бирелгән күрсәтмәләрнең үтәлешен тикшерүдә тоту максатларында», «үткәрелергә мөмкин.» сүзләреннән соң «Әлеге тикшерүләр прокуратура органнары белән килештермичә үткәрелә.» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин